**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 март № 157

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 26 гыйнвар, 20 нче; 2007 ел, 28 апрель, 149 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 38 нче; 2008 ел, 25 июль, 534 нче; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2009 ел, 8 май, 283 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1033 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 533 нче; 2012 ел, 10 март, 205 нче; 2012 ел, 9 июнь, 503 нче; 2013 ел, 18 март, 175 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 946 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 254 нче; 2014 ел, 1 ноябрь, 842 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 736 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалау (01.01*);

инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуы (01.10*);

инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

сәнәгать белән идарә итү (03.01*) (әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада китерелгән эшчәнлек төрләре буенча);

энергия һәм ресурслар саклау белән идарә итү (01.14*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

бюджет процессы белән идарә итү (Татарстан Республикасы бюджеты һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлар) (01.02.1*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

территорияләрне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү (01.05.02*);

Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне тәэмин итү (01.05.01.01*);

шәһәр төзелешен проектлаштыруның төбәк нормативларын әзерләүне тәэмин итү (01.05.03*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының җир ресурслары белән идарә итү (01.07.04*);

билгеләнгән тәртиптә җирләрне категорияләргә кертү, аларны бер категориядән икенче категориягә күчерү белән идарә итү (Татарстан Республикасы милкендә булган җирләргә, шулай ук муниципаль һәм шәхси милектә булган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләргә карата (01.07.04.1*) (дәүләт милкендә, муниципаль һәм шәхси милектә булган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләр өлешендә);

Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе белән – балыкчылык, су объектларыннан һәм су биоресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда (01.06.05*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – билгеләнгән тәртиптә хезмәт белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән – билгеләнгән тәртиптә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда (03.03.03*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән – түбәндәге вазыйфаларны гамәлгә ашырганда:

билгеләнгән тәртиптә урта һөнәри белем бирү белән идарә итү (федераль мәгариф оешмаларында ала торган белемнән тыш) (04.05.06*);

билгеләнгән тәртиптә өстәмә һөнәри белем бирү белән идарә итү (федераль мәгариф оешмаларында ала торган белемнән тыш) (04.05.08*);

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән – Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) (01.15.02*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлеген яраштыру һәм хокукый яктан тәэмин итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тикшерүдә тоту) (02.04.01*);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати ресурсларын формалаштыру белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда (01.15.01.1*).»;

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«юридик затларның документларын карап тикшерә һәм, Министрлыкның эшчәнлек өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган масштаблы инвестицион проектлар реализацияләнгәндә, масштаблы инвестицион проектларның Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясында күрсәтелгән критерийларга, Татарстан Республикасы Президенты Указында билгеләнә торган әлеге критерийларның сыйфат һәм (яки) сан ягыннан күрсәткечләренә туры килүе турында бәяләмәләр проектларын килештерә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\157.docx